



Әнвәр ШӘРИПОВ




# ЧАЛ ГАЛИМ ХАТИРӘЛӘРЕ

## Без төшеп калмадык...

Татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга килгән абитуриентларга шактый житди конкурс үтеп чыгарга туры килде. Без укырга кергән 1960 елны бу бүлеккә бер урынга биш кеше гариза биргән иде. Шуңа күрә имтиханнар барышында шактый кеше төшеп калды, студент булу бәхетенә бик сирәкләр генә ирешә: татар теле бүлегенә бер группа гына – егерме биш кеше генә алдылар. Университетка укырга керү өчен дүрт имтихан бирергә кирәк иде. Мин аларның икесен бишлегә (чит тел – алман телен дә бишлегә бирдем, чөнки мәктәптә аны ныклап өйрәнгән идем), икесен – дүртлегә бирдем. Шулай итеп, миңа университетка (әле ниндиенә! – Ленин укыган университетка!) укырга керү бәхете насыйп булды.

Университетта мин өр-яңа дөньяга эләктем. Анда Равил Фәйзуллин, Шамил Маннапов, Салисә Гәрәева кебек яшь шагыйрьләр, Ким Садыйков, Ленар Җамалетдинов кебек инде тормыш тәҗрибәсе туплаган кешеләр белән таныштым. Безнең факультетта татар студентларының әдәби-иҗат түгәрәге оешты. Аның утырышлары ике атнага бер тапкыр була иде. Без анда үзебез язып килгән шигырь-хикәяләрне укый һәм тикшерә идек. Әсәрләребездән «Әдәби сүз» дигән стена газетасы чыгара идек. Ул газетаның озынлыгы коридор буе дүрт-биш метрга җитә иде. Без икенче курста укыган чакта, иҗат түгәрәгенә Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, ә соңрак Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт кебек яшь шагыйрьләр дә килеп кушылды.

Без икенчеме-өченчеме курсларда укыганда, бервакыт түгәрәккә Башкортстанда туып үскән Шамил Мәхмүдов дигән шагыйрь дә йөри башлады. Аның әдәби псевдонимы – Шамил Анак иде. Ул шигырьләрен яңача, оригиналь фикерләр белән, ак шигырь итеп яза иде. Шул ягы белән ул безнең өчен үзе бер яңалык, бер сихри дөнья кебек булды. Аның, әле чагыштыр-

мача яшь булуына да карамастан, инде Мәскәү дәүләт университетында укып, аны тәмамлаган һәм, тагын да гаҗәбрәге, инде Чехословакиядә, Прага университетында рус әдәбияты предметын укытып кайткан булуы безнең өчен, әле Казаннан башка зур шәһәрләрне күрмәгән авыл балалары өчен, күктән төшкән бер яңалык булып тоелса, ә шундый талантлы, дәрәҗәле кешенең безнең белән аралашып йөрүе аерым бер горурлык хисе дә уята иде. Шулай итеп, студент елларым әдәбият-иҗат түгәрәгендә катнашып, үзара фикерләшеп, бәхәсләшеп, мәш килеп узды.

1963–1964 елның кышкы каникулында без, Равил Фәйзуллин белән икәү, Ленинградка бардык, андагы Эрмитаж һәм башка истәлекле урыннар белән таныштык. Шуннан кайтканда үзебез өчен план кордык: тиз арада турист булып, чит илләр белән танышып кайтырга. Әкренләп сәяхәт өчен акча туплый башладык. Һәм Равил 1964 елның августында ук инде путевка алып, Югославия буенча сәяхәт итеп кайтты. Мин дә озакка сузмадым: август ахырында ук «Польша – Чехословакия» маршруты белән туристлык сәяхәтенә чыгып киттем...

1965 елда университетны тәмамлап чыктык. Төрлебез төрле якка таралдык. Минем Казанда каласым килгән иде дә, әмма ни торырга урыным, ни эшем юк иде. Казаннан китәргә теләмичә, июль – август айларында Казан мехчылар комбинатының «Молодая гвардия» дигән лагеренда пионервожатый булып эшләдем. Ике сменада да миңа бәләкәйләр отряды туры килде. Мин ул отрядны урман буйлап прогулкада да йөртә, хәтта ерак түгел күлгә су керергә дә алып бара идем. Шунда, минем отрядта Павел исемле түгәрәк кенә бер малай бар иде. Ул шулкадәр табигый, эчкерсез бала иде; бервакыт аның башы тирәсендә бал кортлары бөтерелә башлады. Аның кулы белән шул кортларны ничек кууы әле хәзер дә минем күз алдымда тора. Бу балалар белән эшләве миңа рәхәт кенә иде; чөнки дисциплина өчен кайгырасы юк: алар барысы да сүзне тыңлыйлар. Шулай итеп, бу җәйге каникулны мин бик рәхәт итеп, истәлекле итеп уздырдым.

Ә көз җиткәч, мин Биектау район радиосы редакторы булып эшкә урнаштым. Диктор вазифасын да үзем алып бардым. Көн саен райондагы яңалыклар турында сөйли идем һәм хәтта пластинкалардан җырлар да тапшыра идем. Мин анда 1965 елның августыннан ноябрь аена кадәр эшләдем. Ә ноябрьдә, Октябрь бәйрәменнән соң, мине армиягә алдылар. Армиягә китәргә повестка килгәч, мин башта Зәй-Каратайга кайтып, инәкәйләр белән саубуллашып килдем һәм хезмәткә Биектаудан китеп бардым.

## Ленинградта яки «Бәрәңгегә тоз салырга онытканмын»

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшләгәндә мин борынгы татар әдәбияты белгече Шакир абый Абилов белән бер бүлмәдә утырдым. Икебез дә археографик экспедицияләр вакытында табылган кулъязма китапларга тасвирлама яза идек. Моңа кадәр әле бер галим дә кулына алмаган әлеге кулъязмаларны беренче булып уку, алардагы язмалар белән беренче танышу үзе генә дә нинди зур шат-

лык! Ул кульязмаларда нинди генә яңа әсәрләр, нинди генә яңа мәгълүматлар булмый! Бу эшнең, һичшиксез, үз романтикасы бар, һәм аны бары борынгы кульязмаларга гашыйк, шуларга тасвирлама язучы кеше үзе генә тоя ала иде.

Әмма ул кульязмалар еш кына без белгән төркичә генә түгел, ә гарәп һәм фарсы телләрендә дә язылган була. Гарәп телендәгеләренең нинди эчтәлектә икәнлеген сүзлекләр ярдәмендә мин ачыклый да, тасвирлама да яза алам әле, чөнки университетта укыганда безгә гарәп теле дәресләре кергән иде, һәм без, студентлар, гарәп теле турында азмы-күпме белем дә алган идек. Ә менә фарсы теле дәресләре безгә кермәде, аның грамматикасы, лексикасы буенча минем гомумән белемем юк иде. Шуңа күрә институтның татар әдәбияты бүлеге җитәкчесе Нил абый Юзиев, фарсы телен өйрәнеп кайтыр өчен, мине 1975 елда Ленинград дәүләт университетының Көнчыгыш телләре факультетына, атаклы профессор Габдрахман ага Таһирҗанов карамагына алты айга стажировкага җибәрде. Аның бу гамәле өчен мин Нил абый Юзиевка гомерем буе рәхмәтле булып яшәдем һәм хәзер дә бик рәхмәтле, чөнки мин Ленинградта чын мәгънәсендә зыялы, тирән фикерле, олпат галимнәр белән таныштым, алты ай гына булса да алар белән аралашып яшәдем. Бу, әлбәттә, минем өчен, моңа кадәр Казаннан башка зур фән үзәкләрен күрмәгән авыл егете өчен, зур бәхет һәм дәрәҗә иде.

Шуны әйтергә кирәк, минем стажировкада булган вакытым Айдар Юзиев, Нурия (Габделәхәт кызы) Гәрәева һәм тагын берничә студентның Ленинград университетында Көнчыгыш телләре факультетының гарәп теле бүлегендә укыган чакларына туры килде, һәм мин алар белән һәрчак аралашып яшәдем. Бу факультетта алар гарәп телен ныклап өйрәнделәр һәм Казанга чын гарәп теле белгечләре булып кайттылар; Казан галимнәре аларга сокланып һәм хөрмәт белән карыйлар иде.

Ленинградта биш-алты көн яшәгәч, нишләптер мин Казанны, Татарстанны сагына башладым. Гаҗәп бит: менә ничә көн инде, минем беркем белән дә татарча сөйләшкәнем юк: тулай торакта да, урамда да – русча. Рәхәтләнеп үз телемдә сөйләшәсем килә башлады. Ләкин кем белән сөйләшергә? Якынтирәмдә татарча сөйләшерлек беркем дә юк. Шулай итеп мин эчемнән генә үз телебезне сагынып, җирсеп яши башладым. Шулай эчтән генә туган телемне сагынып йөргән бер көнне, мин Нева проспектындагы Торговый кварталга кергән идем, шунда икенче катта йөргән чакта, кинәт халык арасыннан сөйләшә-сөйләшә ике хатын үтеп китте. Шунда берсенең «Бәрәңгегә тоз салырга оныткանмын» дигән сүзләрен ишетеп калдым. И-и, рәхәт тә булып китте инде! Тагын татарчаны ишетим әле дип, бераз артларыннан ияреп тә бардым әле. Аннан, йә мине күреп алып, шикләнә башларлар дип, аларны күзем белән генә озатып калдым.

Миңа соңрак берничә тапкыр Ленинградның Көнчыгышны өйрәнү институтында да булырга туры килде. Мин анда Гарәп теле кабинеты мөдире Әнәс Бакиевич Халидов белән таныштым. Әнәс Бакиевичның әтисе (Бакый Закирович Халидов) Бөгелмә шәһәреннән икән; ул күренекле гарәп теле белгече була һәм 1981 елда Ташкентта рус телендә 654 биттән торган «Учебник арабского языка» дигән

дәреслек бастырып чыгара. Бу китап дистә еллар буена гарәп телен өйрәнү өчен русча чыккан бердәнбер һәм иң популяр дәреслек булып килде. Әнәс Бакиевич белән сөйләшкәндә мин үземнең Лениногорск районыннан икәнемне әйткәч, ул мине үзенең якташы итеп тә кабул итте, институттагы борынгы кулъязмалар һәм фәнни әдәбият белән танышуда миңа киңәшләр бирде.

Ленинградта яшәгән чакта үзем аралашкан кайбер галимнәр турындагы фикерләрем белән уртаклашасым килә.

**Габдрахман Таһир улы Таһирҗанов** (1907–1983). Габдрахман ага – татар халкының күренекле галиме, гарәп, фарсы, төрки әдәбиятлары тарихы белгече. Ул иң элек фарсы-таҗик әдәбияты һәм фарсыча кулъязмалар белгече буларак таныла. Ә соңга таба урта гасырлар Көнчыгыш халыклары әдәбиятлары һәм, беренче чиратта, татар әдәбияты тарихының зур белгече булып китә.

Аның тормыш юлы Габдрахман аганың үзе язган биографиясендә тулы чагыла; рус телендә язылган бу истәлек «Гасырлар авазы» журналында басылып чыкты (2000 ел, № 1, 116-122 битләр). Кыскача гына аның биографиясенә тукталып алам.

Ул 1907 елның 7 февралендә Татарстанның Апас районы Морзалар авылында туган. Авылга «Морзалар» исеме Габдрахман ага шәҗәрәсендә сигезенче буын булган Ураки Морза исеменнән алып бирелгән. Ураки Морза үз чорының атаклы гыйлемле кешесе булган; әлеге гыйлемлелек алар нәселендә буыннан буынга күчеп килгән. Габдрахман аганың бабасы Садыйк та бик белемле кеше булган. Ә Габдрахман аганың әтисе үзенең эшчәнлеге, тырышлыгы белән атаклы булган; ул авылда үзенә йорт, кладовая, өч ат сарае салган, үз коесын булдырган, зур гына яшелчә бакчасы утырткан. Ә кыш көне мәктәптә балалар укыткан; аны авылда мөәзин итеп сайлап куйганнар. Әтисендәге тырышлык һәм эшчәнлек улы Габдрахманга да күчкән. Абыйсына ияреп, ул дүрт яшьтән алып мәдрәсәдә укый башлый; укырга, язарга өйрәнә; монда төрек телен өйрәнә башлый. Бу авыл мәдрәсәсендә ул өч ел укый. 1914 елдан укуын Күрше Урта Балтай мәдрәсәсендә дәвам итә, биредә гарәп язуына төшенә. Буа мәдрәсәсен тәмамлый. 1921 елда, ачлыктан качып, Сормовода кыш уздырганда һәм Мәскәүгә төзелешкә киткәч, рус теле буенча белемен ныгыта.

Соңыннан эш эзләгәндә, Мәскәү, Баку, Ашхабад, Ташкентта була. Төзелештә гади эшче, аннан почтальон, аннан китапханәче булып эшли. Бу еллар дәвамында вакытын бушка уздырмый, үзлегеннән белем ала. Бакуга бәхет эзләп баргач, азербайҗан егетләреннән аларның туган телен өйрәнә. Ашхабад шәһәренең автомашиналар ремонтлау мастерскоенда эшләгәндә төрекмән телен, китапханәгә эшкә күчкәч, үзлегеннән укып, төрекмән әдәбиятын үзләштерә. Социаль гигиена институтына эшкә чакырылгач, төрекмән авылларына сәфәр чыга. Төрекмәннәрнең матди һәм рухи мәдәниятенә, көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә, милли үзенчәлекләренә төшенә. Ул дәүләт банкы хезмәткәрләренә төрекмәнчә дәрес бирерлек дәрәҗәдә җирле халык телен өйрәнгән. Үзбәк телен тиз өйрәнеп, Ташкентта машина-трактор станциясендә русча язылган инструк-

цияләрне үзбәкчәгә тәрҗемә итә. Өч елдан республиканың Җир эшләре буенча халык комиссариатында руsларга үзбәк телен укыта. Бу телләрне өйрәнү аңа соңыннан Шәрыкъның күп гасырлык әдәби мирасына ачкыч табарга ярдәм итә.

1927 елдан ул Ленинградта яши һәм эшли, гарәп шигърияте теориясе буенча дин белгече Муса Бигиевтан дәресләр ала; аның кызына өйләнә. Бу елларда ул шәһәрнең Җәмигъ мәчетендә иң яхшы Коръән укучы була.

1935 елда рабфакның дүртенче курсына укырга керә, аны 1936 елда тәмамлый. 1937 елда, утыз яшендә, А. Жданов исемендәге Ленинград дәүләт университетына фарсы теле бүлегенә имтихан тапшыру өчен килә. Ләкин ул елны университетның фарсы бүлегенә студентлар кабул ителми, Габдрахман ага гарәп теле бүлегендә гарәп телен үзләштерә башлый. Бер елдан, гариза язып, үзе укырга теләгән фарсы бүлегенә күчә. Беренче курсны тәмамлаганда академик И. Ю. Крачковскийга (Коръәнне русчага тәрҗемә итүче) гарәп теленнән Гарәп бүлегенең тулы университет курсы өчен имтихан, үзлегеннән әзерләнеп, берьюлы 18 имтихан һәм зачет тапшыра, һәм беренче курстан туп-туры өченче курска күчерелә. Университетта уку белән бер үк вакытта хореография училищесында төрекмән теле укыта. Диплом язу өчен ул «Котб һәм аның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре» темасына алына, фәнни җитәкчесе – Көнчыгыш илләре тарихы, телләре һәм мәдәниятенең атаклы белгече, СССР Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, Ленинград университеты профессоры Е. Э. Бертельс (1890–1957) була. Шулай итеп, Г. Таһиржанов СССРда беренче булып Котб поэмасын әдәби планда өйрәнә башлый, азербайҗан шагыйре Низаминың (1141–1209) «Хөсрәү вә Ширин» әсәрен Котбның шул ук исемдәге поэмасы белән чагыштыра. 1941 елда Ленинград университетын кызыл диплом белән тәмамлый.

Ватан сугышы башлангач, аны Кызыл Армиянең югары уку йортына укырга җибәрәләр, ул башта Мәскәүдә, аннан Казанда фарсы теле укыта. Күзе начар күрүе аркасында аны армиягә алмыйлар. Ул Ташкентка китә һәм СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтына аспирантурага укырга керә (фәнни җитәкчесе атаклы галим Е. Э. Бертельс була). 1946 елда Ленинградка килә һәм «Котбның «Хөсрәү вә Ширин поэмасы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Ленинградта башта Көнчыгышны өйрәнү институтында, аннан Ленинград университетының Көнчыгыш телләре факультетында фарсы, төрек, гарәп телләрен укыта. 1969 елда «Рудаки иҗаты» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. 1972 елда аңа профессор фәнни дәрәҗәсе бирелә.

Габдрахман ага Таһиржанов барлыгы 90нан артык фәнни хезмәт язган, шулардан 54 хезмәте, шул исәптән биш китабы басылып чыккан. Күп еллар дәвамында Ленинград университетының Көнчыгыш факультеты китапханәсенең кульязма фондларын өйрәнү белән шөгыльләнә, шуның нәтиҗәсе буларак 1962 һәм 1967 елларда «Фарсы-таҗик кульязмаларын тасвирлау» дигән хезмәтләре басылып чыга. 1979 елда аның Татарстан китап нәшриятында «Тарихтан – әдәбиятка» дигән мәкаләләр җыентыгы дөнья күрде. Бу китап урта гасырлар татар әдәбиятын өйрәнү өлкәсенә яңа сулыш

өрде, галимнәр һәм җәмәгатьчелек тарафыннан бик яратып кабул ителде.

Миндә Габдрахман аганың бер хаты саклана. Аның язылу тарихы болай. Ленинградта чакта, беркөнне мин, Габдрахман аганы кафедрада очрата алмагач, Габдерәхим Утыз Имәнинең саф фарсыча язган бер-ике шигырен татарчага тәрҗемә итәргә дип (бу турыда аның белән алдан сөйләшкән идек), ул текстларны кафедра лаборанты Яна Александровнага калдырган идем. Габдрахман ага миңа шулар турында менә нәрсәләр язды (хат гарәп хәрефләре белән язылган):

«Хөрмәтле Әнвәр иптәш!

Сезгә сәламнәрем вә догаларым!

Сез җибәргән Габдерәхим Болгари шигырьләрен Яна Александровна күптән биргән иде. Аның черновигын күптән тәрҗемә итеп куйган идем, ләкин ул канәгатьле булмады. Аның фарсыча шигырьләре, әлбәттә, бик ачык түгел. Сез күчергәндә булган хаталары да бар. Үзенең дә фикерләре ачык бирелмәгән. Күп кенәсен чамаларга туры килә. Гомумән, аңлаешлы булмады. Аларны уйлап утырырга вакыт булмады, эшләр бик күп булды. Ниһаять, рәтләп яздым инде. Отрывкалар дигәнегез – фарсы шагыйрьләреннән күчермә, аларны тәрҗемә кылып булмады. Озак тотканга гафу итәрсез.

Ихтирам белән, Габдрахман».

Бу хат миңа Ленинградтан 1983 елның 19 апрелендә салынган.

Мин инде соңыннан да, Ленинградтан кайтканнан соң да, еллар буе үземнең Габдрахман ага Таһирҗанов белән таныш булуыма горурланып яшәдем. Габдрахман ага 1983 елның 18 декабрендә вафат булган һәм Ленинградның Яңа Волхов мөселман зиратында җирләнгән икән.

**Сергей Николаевич Иванов** (1922–1999). Бу галим татар зыялыларына яхшы таныш: ул әдәбиятыбызның җәүһәрләре – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Йосыф Баласагунның «Котадгу белек», Габдулла Тукайның «Шүрәле» поэмаларын русчага тәрҗемә иткән һәм рус телле укучыларга җиткергән күренекле тәрҗемәче. Ә иң мөһиме – ул бу әсәрләрне шигырь белән, зур сәнгати кимәлдә тәрҗемә итте. Ул чын мәгънәсендә тәрҗемәче-шагыйрь иде. Аның турындагы хезмәтләрдә, аның эшчәнлеген характерлап, болай диелә: «Аның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге, күп белгечләрнең фикеренчә, тюркология фәнендә дә, рус фәне һәм мәдәниятендә дә тиңдәше булмаган бер күренеш. Тәрҗемәче-шагыйрь буларак, ул үз алдына шундый максат куя: төрки телендәге классик поэзия әсәрләренең эчтәлеген, рухын, катлаулы образларын, чагыштыру-метафораларын, сүз уйнатуларын, жанр үзенчәлекләрен саклап тәрҗемә итәргә, моның өчен рус теленең барлык мөмкинлекләрен файдаланырга! Ул тәрҗемәче генә түгел, ә шигъри текстның эчтәлеге белән поэтик сурәтләү чараларының органик бердәмлеген аңлатып бирүче дә иде».

Сергей Николаевич күп еллар буена Ленинград университетының төрки телләр кафедрасын җитәкләде. Мин, стажер буларак, университетның иран телләре кафедрасына беркетелгән булсам да, күршедә генә булган төрки телләр кафедрасы мөдире Сергей Николаевич белән дә танышып алдым. Ул үзе дә минем белән, Казаннан килгән кеше буларак, кызыксынды, Казандагы хәлләр, галимнәр турында сорашты. Шушы алты ай дәвамында без аның

белән шактый еш очраштык. Ул миңа киңәшләр дә бирә иде. Аның миңа әйткән бер сүзен мин гомерем буе истә тотып яшәдем. Ул миңа болай диде: «Жизнь превратна, Анвар Магданурович! Постарайтесь быстрее защитить диссертацию. Не дай Бог, что внесут изменения в положение о защите диссертации». Минем өчен бу алтын сүзләр иде.

Казанга мин аның турында иң җылы хисләр белән кайтып киттем. Берничә ел Казанда яшәгәннән соң, Алабугага күченеп, пединститутта укыта башладым. Шактый еллар узды, мин Ленинградтагы фәнни тормышны сагынып яшәдем һәм бервакыт докторлык диссертациясе язарга җыена башладым. Аны язу өчен 1986 елда институттан өч айлык «фәнни отпуск» алуга ирештем; мине бер айга Ленинградка фәнни командировкага җибәрүләрен сорап гариза яздым. Бу турыда Сергей Николаевичка хәбәр иттем. Ул миңа болай дип җавап кайтарды: (хат кыскартылып китерелә): «Добрый день, Анвар Магданурович! Тема Вашей докторской работы очень достойна, и Вам, конечно же, нужно энергично работать над ней. Приезжайте в Ленинград. Если Вы захотите, то прикомандироваться можно и к кафедре тюркской филологии. Примите мои самые добрые пожелания здоровья и успехов. С уважением, С.Н. 5/IX-86».

Мин Ленинград университеты ректоры исеменә мине Төрки телләр кафедрасына беркетүләрен сорап хат яздым. Сергей Николаевичның икенче хаты шул турыда иде. Миңә ул: «Дорогой Анвар Магданурович! Ваше письмо на имя ректора было получено, и я на нем поставил соответствующую пометку о моем согласии. Вы должны были бы уже получить ответ. Я наведу справки у нас в деканате – когда был послан ответ. Приезжайте, здесь на месте все уладится. Всего Вам доброго! Ваш С.Н. 15/XI – 86».

Шулай итеп, Ленинград университетында командировкада булган чакларда миңа юл күрсәтүче кеше С. Н. Иванов булды. Мин аның белән еш аралашып, киңәшеп яшәдем. Миңа бит әле моңа кадәр беркем дә өйрәнмәгән тема буенча материаллар җыеп, яңа фәнни хезмәт язарга кирәк иде. Ә аңа ничек тотынырга, нинди чыганакларны үзләштерергә? Менә шунда С. Н. Иванов миңа зур таяныч булды, миңа юнәлеш күрсәтте: ярдәм итү йөзеннән, үзе җитәкчелек иткән кафедрада минем докторлык диссертациямнең план-проспектын тикшерүне, фикер алышуны оештырды. Бу миңа зур файда булды: тикшерү вакытында кафедра галимнәре миңа шактый гына кыйммәтле киңәшләр бирделәр. Мин Сергей Николаевичка ихластан зур рәхмәт әйттем; Чаллыга кайткач язган хатымда да аңа рәхмәтемне белдердем. Ул миңа болай дип җавап кайтарды: «Добрый день, Анвар Магданурович! Рад, что Вы увлеченно работаете, и что обсуждение принесло Вам пользу. Когда нужно будет, приезжайте опять... Желаю Вам успехов. Ваш С.Н. 20/IX-87».

Сергей Николаевич минем докторлык диссертациямне тизрәк яклатырга тырыша иде. Мин аңа, аның игелекле киңәшләре өчен, әлеге хезмәтемне яклаганчы да, яклагач та – гомер буе рәхмәтле булып, аның белән якыннан таныш булуыма куанып яшәдем.

**Александр Николаевич Болдырев** (1909–1993) Ленинград университетының иран телләре кафедрасы мөдире иде. Гаҗәеп кешелекле, ярдәмчел галим иде ул. Мин, аңардан рөхсәт алып, берничә тапкыр аның «Иран телләре белеменә кереш» («Введение в иранское языкознание») дигән дәресләренә кереп утырдым. Гаҗәеп лектор иде ул. Лекцияләрне бик кызыклы, мавыктыргыч итеп, тел тарихына караган күптөрле мәгълүматлар китереп, аерым шәхесләр, истәлекләр белән бәйләп, ачык итеп, тәмләп сөйли иде. Мин аның киң эрудициясенә сокланып, дөньямны онытып тыңлап утыра идем. Ул докторлык диссертациямнең темасы белән дә кызыксынды, миңа нинди чыганаклардан файдаланырга кирәклеге хакында киңәшләр бирде.

А. Н. Болдыревның миндә бер хаты саклана. Ул анда болай яза: «Дорогой товарищ Шарипов! Большое спасибо за книжку (мин аңа 1986 елда үзем чыгарган «Габдерәхим Утыз Имәни. Шигырьләр, поэмалар» китабын җибәргән идем) и за любезное письмо. Приятно видеть, как хорошо умеют теперь издавать в Казани. Но прежде всего, хочется поздравить Вас с завершением большого и нужного труда. Издание произведений Утыз Имяни – значительный вклад в изучение культуры татарского народа, заполнение существенного пробела. Насколько могу судить, работа выполнена на высоком филологическом уровне. Как жалко, что не дожил до этой книги наш незабвенный Абдурахман Тагирович! Наверное, он порадовался.

Желаю дальнейших творческих успехов! А. Болдырев. 12. XI. 86».

Александр Николаевич белән һәр очрашкан һәм сөйләшкән чакта үземне аңардан зыялылык һәм олпатлык дәресе алган кебек тоя идем.

**Михаил Николаевич Боголюбов** (1918–2010). Ул иран телләренең зур белгече иде. 1981–1991 елларда Ленинград университетының иран филологиясе кафедрасы мөдире, ә 1960–1995 елларда (35 ел!) Көнчыгыш телләре факультеты деканы булып эшләде. 1966 елның 1 июлендә СССР Фәннәр академиясенең Тел һәм әдәбият бүлегенә әгъза-корреспондент итеп, ә 1990 елның 15 декабрендә СССР Фәннәр академиясенең Тел һәм әдәбият бүлегенә академик итеп сайланды.

Әйтергә кирәк, Ленинград университетының Көнчыгыш телләре факультетының үзенең зур тарихы бар. Ул безнең илебездә генә түгел, ә дөнья күләмендә Көнчыгыш телләрен өйрәнүнең зур бер фәнни үзәге булып санала. Ул 1703 елда ук ачыла. Анда бөтен халыкара күләмдә танылган тирән фикер ияләре, зур галимнәр эшли.

Михаил Николаевич Ленинград университетының әнә шундый зур тарихлы факультетының деканы, ягъни «хуҗасы» булып эшләде. Аның үзенең берничә урынбасары бар иде. Мәсәлән, анда командировкада булганда минем яшәү, ягъни торак мәсьәләсен Михаил Николаевичның торак-көнкүреш мәсьәләләре буенча урынбасары хәл итте, аның буенча миңа деканның үзенә кереп торуым да кирәк булмады.

Михаил Николаевич озын буйлы, мәһабәт, сокланлгыч бер зыялы кеше, интеллигентлык үрнәге иде. Йөргәндә дә ул үзен бик төз һәм горур тота. Минем үз гомеремдә никадәр озын буйлы ир-атларны очратканым булды,

ә Михаил Николаевич кебек затлы, горур, соклангыч башка кешене күргәнем булмады. Җыелышларда да аның президиумда ничек утырганын күрсәгез, сокланмый кала алмас идегез. Бервакыт миңа аның белән бергә эскалаторда метрога төшәргә туры килде. Төшеп җиткәч, мин бер яктагы поездга утырырга киттем, ул икенче яктагы поездга юнәлде. Шунда мин аның метро поездына утырып китүен соклanып карап торган идем.

Ул безнең профессор Габдрахман ага Таһирҗановны бик хөрмәт итә иде. Үзенең шул хөрмәтен белдереп, ул «Как человек, как ученый Абдурахман Тагирович уникален» дигән мәкалә язды һәм аны «Гасырлар авазы» журналында бастырды («Эхо веков», 2000, № 1/2. – 115 -116 бб.). Бу мәкаләдә М. Н. Боголюбов Габдрахман ага турында болай яза: «По природе Абдурахман Тагирович был наделен трудолюбием, неординарным умом, скромностью и терпением, добротой и отзывчивостью. Это был жизнерадостный человек с твердым и непреклонным характером. Он неизменно следовал кодексу строгих нравственных правил, выработанному им самим. Одним он казался архаичным, другие почитали его как пример».

Михаил Николаевич минем күңелемә гомер буена соклангыч кеше булып кереп калды.

Ленинградта танышкан галимнәр, зыялылар белән мин гомерем буе горурланып һәм элемтәдә булырга тырышып яшәдем. Ленинград истәлекләре хәтта әле бүген дә минем күңелемә җылылык биреп тора.

## Ялгыштым шул...

Хаталарны күп ясадым мин тормышта. Эреле-ваклы хаталарым күп булды. Аларның күбесе минем тормышта тәҗрибәсезлегем һәм үз алдыма олы максат куеп яшәмәвем аркасында ясалды.

Тормышымдагы иң зур һәм соңыннан тискәре нәтиҗәләре иң күп булган хатам – минем үз теләгем белән Казанны, әдәбият һәм фән дөньясын ташлап, провинциягә китеп баруым булды. Башкалада яшәүнең кадерен белмәгәнмен. 1978 елда, ИЯЛИне ташлап, Алабуга пединститутына эшкә күчеп киттем. Нил Гафурович Юзиев мине никадәр, айлар буена китмәскә үгетләде, ә мин һаман үземнекендә тордым: «Китәм!» – дидем. Нинди кирелек булгандыр миндә ул чакта, аны мин хәзергә кадәр аңлый да, аңлата да алмыйм. «Казаннан башка да дөньяда тормыш бар бит әле. Нигә Казаннан башка яшәп карамаска?» – дип уйладым мин ул чакта. Ә ул уй хата булган икән. Мин бит Казаннан нәкъ менә фән дөньясында зур эшләр башкара алырлык чакта, нәкъ менә фән кешесе булып өлгереп, формалашып җиткән вакытта китеп бардым. Һәм башкаладан киткәч, мин Казан тормышыннан бик күпкә ваграк, фәннән бик ерак проблемалар, гамәлләр белән шөгыльләнергә мәҗбүр булдым. Провинциядә инде мин фән белән шөгыльләнә алмадым, мине башка мәшәкатьләр чолгап алды...

Казаннан китүем болай булды. 1978 елның көзе иде ул. Мин Казанда Татарстан урамы белән Тукай урамы чатында басып торам. Яңгыр ява. Аяк асты пычрак, хәтта ботинкага эләгә (ул вакытта әле Казанда шәһәрне чиста то-

ту турында бик уйламыйлар иде). Бер тынычлык та юк: бертуктаусыз машиналар чаба, тырылдап трамвай узып китә. Ул чакта мин Казан университетының аспирантлар яши торган тулай торагында бер бүлмәдә кунып яши идем. Әмма комендант китәргә куша, чөнки мин инде аспирант түгел, ә Фәннәр академиясендә, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшлим. Үземә квартир эзлим. Әмма әле табып булмый. Мин инде беренче хатынымнан аерылган (без Гөлшат белән шәһәр ЗАГСына барып, гариза биреп аерылыштык). Яңа гаилә корыр өчен кешем – йөргән кызым да юк. Аннан мин Казан кызларына бик ышанып та житмим... Таяныр кешем дә юк. Һәм шул чакта мин ныклы карарга килдем: «И-и, нигә соң әле мин монда жәфа чигеп яшәп ятам. Казаннан башка җирдә дә тормыш бардыр бит. Китәргә кирәк миңа бу Казаннан...» Казаннан читтә мин өр-яңа тормыш башлап җибәрәм кебек тоелды миңа.

Һәм әкренләп үземнең шул карарымны тормышка ашыра башладым.

Бер көнне (ноябрь ае иде) мин эшли торган институттагы фәнни конференциядә Алабуга педагогия институтының ректоры Тәлгат Нәбиевич Галиуллин чыгыш ясады. Тәнәфескә чыккач, мин аның янына бардым һәм аңардан: «Сездә берәр төрле эш булмасмы?» – дип сорадым. Ул мине бераз белә иде. «Әйдә, кил! Татар әдәбияты буенча өлкән укытучы урыны бар», – диде. «Уку елы башланды бит инде. Чынлап та, сәгатьләр булырмы соң?» – дигәнгә, ул: «Булыр. Булыр. Табарбыз», – дип җавап бирде. Түләү ягы да ярыйсы гына икән. Казанда кече фәнни хезмәткәр булып эшләүче мине аның акчасы да кызыксындыра иде, әлбәттә. Һәм мин Тәлгат Нәбиевичка: «Ярар, алайса, мин шушы арада мондагы эштән чыгам да сезгә киләм», – дидем.

Һәм шулай эшләдем дә. Икенче көнне үк мин эштән китәргә дип гариза язып, институтның үзем эшли торган татар әдәбияты секторы җитәкчесе Нил Гафурович Юзиев янына кердем. Нил абый моңа бик гаҗәпләнде. Мин аңарга китүемнең сәбәбе итеп үземнең торыр урыным да юклыгын әйттем. Ул, әлбәттә, моны белә иде, әмма миңа ярдәм итә алмый иде, чөнки ул елларда Казанда квартир мәсьәләсе бик авыр, минем кебек яшәү өчен бер почмагы да булмаган кешеләр шактый иде. Ул минем гаризама кул куймады. Мин аңарга үземнең Тәлгат Нәбиевич белән сөйләшкәнемне һәм аның мине Алабугага чакырганын да әйттем. Әмма Нил абый барыбер кул куймады: «Бераз уйла әле. Дөрес эшлисеңме син?» – диде. Ә минем инде ул чакта әллә ни ныклап уйлап торасым да килмәде: «Чакыралар икән, барырга кирәк. Һәрхәлдә, анда Казандагыга караганда әйбәтрәк булачак», – дип уйладым. Бер-ике көн узгач, мин гариза тотып тагын аның янына кердем. Минем күңелем инде әле үзем белмәгән Алабугада йөзә иде. Бу юлы да Нил абый гаризама кул куймады: аның мине җибәрәсе килми иде. Шулай бер айга якын вакыт үтте. Нил абый кул куймый да куймый. Инде нишләргә? Минем мондагы эштән дә күңелем кайтты. Шулай кат-кат бер үк сорау белән янына кергәч, беркөнне Нил абый миңа: «Ярар инде алайса. Үзең теләгәч, мин нишли алам», – диде дә гаризама кул куйды.

Ләкин мин ялгыштым: мин зур өметләр баглаган кешем (беренче мәхәббәтем түгел!) мине аңлый да

алмый торган, минем белән нормаль гаилә корырга теләге дә булмаган кеше булып чыкты. Чөнки ул үзе башка егеткә гашыйк булып, гел шуның турында гына уйланып яшәүче кеше булып чыкты. Хәзер уйлыйм-уйлыйм да, шундый нәтиҗәгә киләм: минем Казаннан китүемә этәргеч бер көч – ул минем беренче мәхәббәтемнең кире кагылуы булгандыр, дим. Минем беренче мәхәббәтем Казанда яши иде. Ә ул минем мәхәббәтемне кире какты. Мин җавапсыз мәхәббәтнең бөтен ачысын татыган Мәҗнүн хәлендә идем...

Һәм мин, Казаннан китеп, билгесезлеккә атладым. Бу чынлап та билгесезлек иде – бу минем хәзерге фәнни эшемә дә, фәнни үсешемә дә аяк чалу булып чыкты. Мин үз теләгем белән, ныклап уйлап тормастан, үземнең фәнни киләчәгемә аяк чалдым. Мин хәзер дә аңа үкенәм һәм: «Бу минем тормышымдагы иң зур ялгышым, хатам булды», – дип уйлыйм. Инде күп еллардан соң, 2000 еллар тирәсендә, бервакыт Казанга баргач, үзем эшләгән Тел, әдәбият һәм тарих институтына кергәч, минем белән университетта бер группада укыган һәм аспирантурадан соң ИЯЛИдә эшләргә калган филология фәннәре докторы Фирдәвес Гарипова миңа әйтеп куйды: «И-и, Әнвәр, нигә шул чакта минем белән киңәшмәдең нәрсә эшлим икән дип? Мин сиңа китмәскә киңәш биргән булыр идем. Казанда калсаң, син бит инде членкорр. дәрәҗәсенә ирешкән була идең», – дип, үзенең үкенечен белдерде. Дөньяга күземне ачыбрак карарга кирәк булган...

Менә инде Казаннан киткәнемә дә утыз елдан артык вакыт узды, ә мин әле һаман Г. Ибраһимов исемендәге институтны сагынам, аны төшләремдә күрәм. Озак вакытлар (дистә еллар) буе минем төшемә үзем эшләгән институт, аның коридорлары, бүлмәләре һәм үзем эшләгән бүлмә кереп йөдәтте. Мин төшемдә шатланам: мин яңадан ИЯЛИдә эшлим икән, һәм миңа бик рәхәт икән. Ә уянып китсәм: мин – Чаллыда. Тирә-ягым – Казан түгел, ә Чаллы мохите – Казанның төсе дә юк! Һәм мин, уфтанып, ирексездән Чаллының гадәти тормышына кереп китәм. Андый төшләр күп кабатланды. Ләкин берни эшләр хәл юк: мин инде күптән, үземнең тормышны икенче юнәлешкә салып, Чаллыда яшәп ятам: ә Казан – хыялда гына кала. Мин Казанны сагынып яшим. Мин яңадан Казанга күчү турында да уйлап карадым, ләкин тормыш шартлары гел каршы килеп торды. Мин кирәкле моментны тотып ала алмадым: «Поезд ушел!» – диләр андый вакытларда.

## «Карарга кирәк!»

***Галим Шакир Абилов турында истәлек***

1971 елда Казан университетында аспирантураны тәмамлагач, мине Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына кече фәнни хезмәткәр итеп эшкә алдылар (дөресрәге, мин аспирантураны бетерер алдыннан минем фәнни җитәкчем Хатип ага Госман алдан ук минем кайда эшләвем турыда сөйләшеп куйган булган). Һәм менә мин 1971 елның 1 сентябреннән алып шушы фәнни институтта эшли башладым.

Минем эш урыным институт бинасының икенче катындагы 51 нче бүлмәдә булып чыкты. Беренче тапкыр

ул бүлмәгә кергәндә, 40-45 яшьләр чамасы бер абый утыра иде – ул Шакир Шиһапович Абилов булып чыкты. Ул мине бик җылы каршылады. Бүлмәдә утырып эшләргә ике өстәл иде; миңа шунын берсен бирделәр. Биредә шуны искәртергә кирәк: ул еллардан соң инде күпме сулар акты, күпме вакыт үтте; шуңа күрә ул вакыттагы хәлләрнең күпмедер өлеше инде хәтердән җуелган да. Шулай да сакланып калганнарын өзек-өзек кенә булса да кәгазьгә төшереп куярга булдым.

Мин җиде ел буе Шакир абый белән бер бүлмәдә утырып эшләдем. Без бик дустанә эшләдек. Күпме еллар бергә булып та, мин аның бер вакытта да тавышын күтәреп сөйләшкәнен дә, кызып киткәнен дә яки ачуланышканын да күрмәдем. Табигате белән ул бик тыныч кеше иде. Бәхәсле мәсьәләләр килеп чыкканда да, ул аны исе китмичә генә кабул итә, үзенә каршы кешенең сөйләгәнен тыныч кына тыңлый, бәхәскә керми, ә нәтиҗә ясаган кебек итеп: «Карарга кирәк! Карарга кирәк!» – дип әйтеп куя иде дә, шуның белән бәхәсле мәсьәләгә нокта куелган кебек була иде.

Ул үзенең бөтен гомерен борынгы татар әдәбиятын өйрәнүгә багышлаган сирәк кешеләрнең берсе иде. Безнең аның белән сөйләшү-фикер алышуларның темасы да, нигездә, борынгы татар әдәбияты, фән мәсьәләләре белән чикләнә иде. Шунлыктан мин шактый вакыт аның кайда, нинди фатирда торуы, гаилә хәле турында да белми яшәдем: үзеннән соравы уңайсыз; ә сөйләшкәндә ул тема читтә кала иде. Бары бераздан гына, аның башка кешеләр белән сөйләшкәндә гаилә хәлләре темасы кузгатылса, шуларга Шакир абыйның җавапларыннан гына мин аның гаиләсе хакындагы кайбер мәгълүматларны алгаладым. Бүген инде алары да хәтеремнән җуелып беткән.

Абилов Шакир Шиһапович (1915–2004), әдәбият белгече, филология фәннәре кандидаты (1961), ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1964). 1938 елда Оренбург педагогия институтын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1958–1986 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли. Мөхәммәдьярның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнә, «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге») һәм «Нуры содур» («Күңелләр нуры») поэмаларын бүгенге әдәби телгә күчерә, басмага әзерли: кереш сүз, искәрмәләр, комментарийлар яза һәм сүзлек төзи. «Мөхәммәдъяр. Нуры содур» дигән китап бастырып чыгара (Казан: Татар. кит. нәшр. – 1997. - 334 бит). Борынгы татар әдәбиятына караган Баласагуни, Кол Гали, Харәзми, Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб, Мәүла Колый иҗатлары турындагы хезмәтләр авторы. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр белән бүләкләнә. Хезмәтләре: Борынгы татар әдәбияты. Казан, 1963 (автордаш); Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Том 1 (автордаш). Казан, 1984.

## Бертуган абыем кебек иде

***Нил Юзиев турында истәлек***

Нил Юзиев минем Казан университетындагы укытучым һәм мине кулымнан житәкләп әдәбият фәне өлкәсенә алып керүче остазым булды. Бөтен гомеремне әдәбият фәненә багышла-

вым белән мин үземне нәкъ менә Нил абыйга бурычлы дип саныйм.

Укытучым Нил абый белән танышуым 1960 елдан соң, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергәч булды. Татарстанның бай табигатьле Ютазы якларында туып-үсеп, укып-тәрбияләнеп, татар әдәбиятын ихлас күңелдән яратып үскән бер авыл егете буларак, мин университетта үзебезгә белем бирүче Хатип ага Госман, Диләрә апа Тумашева, Мирфатыйх абый Зәкиев, Әнвәр абый Ахунҗанов һәм башка укытучыларга чиксез сокланып, тирән ихтирам белән карый идем. Минем өчен аларда, без –яшьләрне үзләренә тартып тора торган ниндидер бер сихри көч, зур тылсым бар кебек тоела иде. Соңыннан гына, инде үзем төрле вузларда укыта башлагач кына, мин аңладым: «тылсым» дигәнем ул аларның үзләре укыта торган фәннәрне тирәнтен белүләре, аларның еллар буе тормышның кырыс каршылыкларын җиңеп килеп туплаган белем һәм тормыш тәҗрибәләре, энциклопедик белемнәре булган икән. Алардагы шушы белем запасын үземдә дә булдырырга теләп, мин укырга керүемнең беренче көннәреннән үк гыйлем диңгезенә чумдым.

Ул елларда университетның татар бүлеге (күпчелек кеше татар теле һәм әдәбияты бүлеген кыскалык өчен шулай атап йөртә иде) Татарстан күләмендә татар теле, татар әдәбияты өлкәләрендә фәнни-иҗади кадрлар әзерли торган иң абруйлы бердәнбер үзәк булып санала иде. Студентлар арасында инде «стажлы» абитуриентлар, ягъни инде Совет Армиясендә хезмәт итеп кайткан яки моңа кадәр төрле урыннарда – мәктәптә укытып, газета-журнал редакцияләрендә эшләп алган кешеләр белән беррәттән әле быел гына урта мәктәпне тәмамлап чыккан, мыек төртеп кенә килә торган яшьләр дә була иде. Ул елларда беренче курс студентлары өчен шундый бер кагыйдә кертелгән иде: татар бүлеген тәмамлап чыккан күпчелек белгечләрнең соңыннан барыбер Казандагы төрле газета-журнал редакцияләрендә, китап нәшриятында, радио-телевидение өлкәсендә эшләргә калуларын күздә тотып һәм «стажсыз» студентларның соңыннан бер кабинеттан икенче кабинетка, ягъни мәктәп партасыннан – вузга, вуздан – редакцияләргә генә күчеп утыруларын һәм шуның белән газета-журнал редакцияләренә халык тормышын, хезмәтне, производствоны күрмәгән-белмәгән белгечләр хәзерләп чыгаруны булдырмас өчен, «стажсыз» студентларны беренче курста нинди дә булса берәр производство өлкәсендә эшләп укырга мәҗбүр иттеләр. Шулай итеп, мин, «стажсыз» студент буларак, бер ел төзелештә буяучы (маляр) булып эшләп укыдым һәм университет студенты рәвешендә укуның бөтен тәмен-ямен үз җилкәмдә бары тик икенче курста гына татый башладым. Бер ел эшләгәннән соң, миңа уку тансыкланган иде булса кирәк, шуңа күрә икенче һәм өченче курсларда мин фәннәрнең иң тирән чоңгылларына төшеп үзләштерә башладым. Минем бу тырышлыгымны беренче булып Нил Гафурович Юзиев күреп алды: өченче курс азагында ул миңа соңгы дүртенче һәм бишенче курсларда үземә махсус төзелгән программа буенча, ягъни үз термины белән әйткәндә, индивидуаль план буенча укырга тәкъдим итте. Мин, әлбәттә, моңа бик шатланып риза булдым.

Нил абый студентларга карата

бик игътибарлы, ягымлы, кешелекле, ярдәмчел була белә иде. Әле дә хәтеремдә, ул елларда Нил абый күбрәк түгәрәк күзлек киеп йөри иде.

Мин язучылык хезмәте белән бик кызыксына идем, язучылык эшенең серенә төшенәсем килә иде. Шушы теләгемне сизепме, өченче курста Нил абый миңа өйрәнер өчен «Язучының иҗат процессы, иҗат психологиясе мәсьәләләре» дигән тема бирде. Мин, үзем кебек үк индивидуаль план белән укыган Равил Фәйзуллин, Фирдәвес Гарипова, Нил Гарифуллиннар кебек үк, «стажлы» студентлар белән бары тик уку планындагы төп предметларның лекцияләренә һәм практик дәресләренә генә йөрергә, ә махсус курслар һәм махсус семинар дәресләренә килгәндә исә, үзем алган тема буенча өстәмә предметлар үзләштерергә тиеш булдым. Шулай итеп, Нил абый ул елларда миңа өстәмә предметлар итеп «Язучының иҗат процессы», «Иҗат психологиясе мәсьәләләре», «Әдәби әсәрне анализлау», «Хәсән Туфан иҗаты», «Татар әдәби-эстетик фикеренең үсеше» кебек махсус ун предмет укытты. Диплом темасы итеп тә ул миңа «Язучының иҗат процессы мәсьәләләре» дигән теманы бирде. Дүртенче курста мин шушы теманың нигездә теоретик өлешен өйрәнү белән шөгыльләндем.

Диплом язу өчен, әлбәттә, бу теманы теоретик үзләштерү генә җитми, ә шулай ук әле тагын кайсы да булса берәр язучының иҗат лабораториясенә кереп, шул язучының иҗат итү процессының үзенчәлекләрен дә өйрәнергә кирәк иде; ул язучының үзе белән очрашып сөйләшү, әсәрләренең караламалары белән җентекләп танышу да соралып тора иде. Башта без Гомәр ага Бәширов иҗатына тукталдык һәм, диплом нигезенә аның «Сиваш» повестен алып, фәнни хезмәтне Гомәр аганың граждannар сугышы турындагы истәлекләренә, «Сиваш» повестеның караламаларына нигезләнеп язарга уйладык. Әмма Гомәр ага белән сөйләшкәч, бу әсәрнең вариант һәм караламалары сакланмаганлыгы, диплом өчен кирәкле материалларның җитәрлек булмавы ачыкланды. Шуннан соң Нил абый Хәсән Туфан белән сөйләште. Хәсән ага ризалык бирде, һәм мин Хәсән Туфан иҗат лабораториясен өйрәнә башладым.

Бишенче курста укыганда мин, алдан сөйләшеп кую буенча, берничә тапкыр Хәсән аганың Маяковский урамындагы фатирына барып, сәгатьләр буе аның иҗаты, әсәрләре, ул әсәрләрнең язылу тарихы, әдәби иҗат серләре турында сөйләшеп утырдым. Ул сөйләшүләр болай оештырыла иде: гадәттә мин, алдан сөйләшеп кую буенча, Хәсән ага фатирына иртәнге сәгать уннар тирәсендә бара идем дә, без сәгать уникеләргә, ә кайчакта сәгать берләргә кадәр сөйләшеп утыра идек. Ул миңа үзенең сакланып калган бөтен караламаларын күрсәтте, теге яки бу җыентыгын язу ниятенең үзендә кайчан һәм ни сәбәпле барлыкка килүе, аны ничек иҗат итүе турында сөйләде. Әлбәттә, безнең сүз күбрәк аның сөргән елларындагы тормышы һәм иҗаты турында бара иде. Шул вакытта ул миңа үзенең төрмәдә чакта кайбер шигырьләрен папирос кәгазьләренә язып, ипи эченә тыгып саклауларын да, ничек итеп үтә күренмәле кәгазьгә төссез кара белән язуларын да һәм башка күп нәрсәләрне сөйләде. Шул хатирәләрне искә төшергәндә Хәсән ага, дулкынланып, тәмәке тартырга тотына иде;

папирос тоткан имән бармагы тәмәке утыннан бераз саргаеп та калган иде. Нил абыйның күрсәтмәсе буенча, мин Хәсән ага сөйләгәннәрне үз дәфтәремә, аның үзеннән рөхсәт алып кына, язып барырга тиеш идем һәм мин шулай эшләдем дә: ул сөйләгәннәрнең кайберләрен генә дәфтәремә теркәп бардым (ул вакытта әле магнитофон лентасына яздыру, безгә – студентларга – килеп җитмәгән иде). Шунысы кызганыч, үземнең ул язмаларымны мин, Казанда бер фатирдан икенче фатирга күчеп йөри-йөри, бүгенге көнгә кадәр саклый алмаганмын. Ул язмаларны, әлбәттә, мин үземнең диплом эшенә керттем: әмма диплом эшенә инде Хәсән аганың сөйләгәннәре аның үзе әйткән җөмләләре белән түгел, ә билгеле бер дәрәҗәдә әдәбиләштеребрәк, үзгәртелебрәк кертелделәр.

Хәсән ага белән һәр сөйләшер алдыннан без Нил абый белән ул әңгәмәнең планын төзи идек, һәм һәр сөйләшүдән соң мин фәнни җитәкчемә безнең әңгәмәнең ничек баруы турында билгеле бер хисап бирә идем. Андый вакытларда Нил абый миңа Хәсән ага белән алдагы очрашуда тагын нинди әсәрләр тарихы турында, иҗат психологиясенең кайсы мәсьәләләре хакында сөйләшергә кирәклеге турында күрсәтмәләр бирә иде. Шулай итеп мин Хәсән ага Туфанның иҗат лабораториясен, аның иҗат үзенчәлекләрен нәкъ менә Нил Юзиев күрсәтмәләре нигезендә шактый тулы итеп өйрәнә алдым. Нәтиҗәдә, бишенче курс ахырына минем тарафтан «Хәсән Туфан иҗат процессының кайбер мәсьәләләре» дигән темага күләме, машинкада басылган 222 биттән һәм кушымтадан да торган диплом эше язылды. Нил абыйга мин, үземне өченче курста ук «күреп алып», шундый кызыклы һәм иҗтимагый әһәмияте булган фәнни тема биргәне өчен, тормыш юлымда Хәсән ага Туфан кебек олы, олпат шагыйрь белән очраштырганы өчен гомерем буе рәхмәтле булып яшәдем.

Шуны да өстәргә кирәк, Нил абый Хәсән ага Туфанга, аның иҗатына аеруча зур хөрмәт һәм ихтирам белән карый иде. Аның мондый мөнәсәбәтен мин әлеге диплом эшен язу чорында да, аннан соң да тоеп, сизеп яшәдем. Мәсәлән, инде шактый еллар үткәч (бу 1979 еллар ахырында булды), мин, яза торган фәнни мәкаләм турында киңәшләшер өчен, Нил абыйның чакыруы буенча, аларның Аккош күлендәге дачаларына киттем. Җәйнең матур бер көне. Язучыларның дачаларына барып җиткәндә, кояш тәгәрәп төшеп бетә язган иде инде. Бакчада сүрән, дымсу һава. Нил абыйларның дача йортлары, капкадан кергәч, әллә ни ерак түгел. Мин килгәндә, Нил абый чәчәкләргә су сибеп йөри иде. Күрештек, хәләхвәл сораштык. Нил абыйларның бакчасы Хәсән ага Туфанның бакчасы белән янәшә генә икән. Хәсән ага үзе әле килмәгән. Шунда Нил абый миңа, бик нечкә һәм бик нәфис бер нәрсәгә кагылган шикелле итеп: «Менә, кара әле, Хәсән ага нинди чәчәкләр ярата», – дип, Хәсән ага бакчасындагы чәчәкләрне дә бик зур хөрмәт белән күрсәтеп йөргән иде.

Хәсән ага Туфанга булган бу олы хөрмәтен Нил абый үзенең соңгы сулышына кадәр саклады. 1981 елның җәендә мин, Казанга килгәч, Нил абыйларның йортларына киттем. Хәсән ага Туфанны җирләп кайткан бик ямансу көннәрнең берсе иде бу. Минем фатирга килеп керүем булды, Татарстан телевидениесеннән Хәсән Туфан

тормышына багышланган тапшыру башланды. Шунда без, әле хәл-әхвәл дә сорашып тормыйча һәм кунакчыл Дамирә апаның безне өстәл янына чакыруына да җавап биреп тормастан, шул тапшыруны беткәнгә кадәр тын да алмыйча бергә караган идек...

Нил Юзиев белән минем тагын бер тапкыр якыннан торып аралашуым Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән елларымда булды. Казан университетының татар әдәбияты кафедрасында олы, хөрмәтле галимебез Хатип ага Госман җитәкчелегендә 1968–1971 елларда аспирантурада укыганнан соң, мин 1971 елның 1 октябреннән СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалының шушы алда әйтелгән институтында, әдәбият секторында фәнни хезмәткәр булып эшли башладым. Ул вакытта әдәбият секторын галим Хәсән Хәйри җитәкли иде. Әмма бераздан, Хәсән ага Хәйри лаеклы ялга киткәч, әдәбият секторын җитәкләргә университеттан Нил Юзиевны чакырып китерделәр. һәм мин тагын үземнең элекке фәнни җитәкчем белән бергә эшли башладым. Әдәбият секторында мин Нил абый җитәкчелегендә бары тик биш кенә ел эшләп кала алдым.

Кандидатлык диссертациямне Хатип ага Госман тәкъдим иткән тема – XVIII–XIX гасырлар татар шагыйре Габдерәхим Утыз Имәни иҗатына багышлап язуым сәбәпле, бу елларда инде мин элек өйрәнгән темамны үзгәртеп, урта гасырлар татар әдәбияты мәсьәләләре белән шөгыльләнә башлаган идем.

Әдәбият секторы җитәкчесе булып Нил абый Юзиев эшли башлагач, бу бүлекнең бөтен йөзе һәм эшчәнлеге үзгәреп киткән сыман тоелды. Иң элек сектор хезмәткәрләре эшли торган фәнни темалар әкренләп шул елларда аеруча актуаль булган темалар белән алмашына башлады, сектор утырышларын ай саен үткәрү гадәткә керде һәм башкалар. Аеруча шуны әйтергә кирәк: нәкъ менә Нил Юзиев җитәкче булып эшләгән елларда, әдәбият секторы галимнәре чын максатчан эшләделәр һәм халкыбызга «тау кадәр» фәнни хезмәтләр бирделәр. Әйтергә кирәк, Нил Юзиевның әдәбият секторы җитәкчесе булып эшләгән еллары, шул елларда ул кылган гамәлләр, аның фәнни хезмәтләре һәм шул еллардагы әдәбият секторы галимнәре эшләгән эшләр һәм аларның иҗтимагый әһәмияте – боларны барлау, анализлау һәм аларга бәя бирү ул үзе бер зур тема, үзе бер фәнни хезмәт язуны сорый торган өлкә. Мин биредә аларның барысы турында да бәйнә-бәйнә язуны үземә максат итеп куймыйм, бары тик берничә моментка гына тукталып китәсем килә.

1973–1978 елларда мин Нил абый белән, эшнең һәр көнендә очрашып, якыннан аралашып яшәдем. Фәннең дә, тормышның да күп кенә мәсьәләләре турында аның белән киңәшләштем, фикерләштем. Минем бу елларда язылган һәм басылып чыккан барлык фәнни һәм публицистик мәкаләләремдә, һичшиксез, Нил абыйның да билгеле бер күләмдә өлеше бар.

Ул фәндә барыннан да элек масштаблылыкны, тирәнлекне һәм конкретлыкны ярата иде. Әдәбият секторы мөдире булып эшли башлаган елында ук ул, мәсәлән, мине, урта гасырлар татар әдәбияты мәсьәләләрен махсус өйрәнүче яшь галим буларак, Ленинградка, Көнчыгышны өйрәнү институтына фәнни командировкага җибәрде. Ул

чакта Нил абый миңа шул институтның китапханәсендә саклана торган, мин өйрәнә торган темага, ягъни XVIII гасыр татар әдәбиятына мөнәсәбәтле кулъязма чыганаклар белән танышып, иң кирәклеләрен күчереп алып кайту эшен йөкләде. Нәкъ менә Нил Юзиев минем аңыма, фән проблемаларын өйрәнгәндә үзең өйрәнә торган өлкәгә караган фәнни әдәбият һәм чыганакларны Татарстаннан гына эзләмәскә, ә киң дөньяга чыгарга – Мәскәү, Ленинград кебек зур фәнни үзәкләрдәге, ә инде мөмкинлек булса, хәтта чит илләрдәге чыганаклар белән дә эш итәргә кирәклеге турындагы фикерне сеңдерде. Һәм мин, аспирантураны бетерсәм дә, әле олы фән дөньясында ниләр барлыгын үз күзем белән күрмәгән, башка милләт галимнәре белән әле якыннан аралашмаган, яңа гына «аякка басарга» өйрәнеп килгән яшь галим, Ленинградка барып, андагы кулъязма чыганаклар, М. Е.Салтыков-Щедрин исемендәге Публичный китапханәдәге, үзем барган институттагы һәм башка фән үзәкләрендәге сирәк очрый торган фәнни хезмәтләр белән танышып, Шәрыкне өйрәнүче зур галимнәр белән танышып-аралашып, фикер алышып, рухи һәм фәнни яктан баеп кайттым. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән дәвердә Нил абый мине ( мине генә түгел, ә секторда эшләүче яшь галимнәрнең барысын да!) мондый командировкаларга ел саен диярлек җибәреп торды. Боларның барысы өчен дә мин Нил абый Юзиевкә гомерем буе рәхмәтлемен һәм аның якты истәлеге каршында баш иям.

Бервакыт, 1976 елда, Нил абый миңа, институтка Таҗикстаннан килгән З. Ш. Хәсәнованың «Соми и теория эпистолярного стиля в таджикской литературе XIX века» дигән авторефератка бәяләмә язарга кушты. «Эчтәлеген укы да үз фикереңне яз!» – диде, башка күрсәтмә бирмәде. Ә минем моңа кадәр бер дә андый бәяләмә язганым юк иде әле, беренче язуым, җитмәсә рус телендә язарга кирәк. Авторефератны укып чыктым да ничек язарга дип баш вата башладым. Авторефератта анализлана торган намә, ягъни хат жанрындагы таҗик әдәбияты, беренчедән, миңа таныш та түгел, (әмма ул әсәрләрнең урта гасырлар төрки-татар әдәбиятындагы шундый ук хат жанрындагы әсәрләр белән охшашлыгы шактый зур иде), икенчедән, минем әле русча фәнни язу стилем дә формалашып җитмәгән иде. Шул сәбәпле бу бәяләмәне язу өстендә мин шактый озак баш ваттым. Никадәр китап, фәнни хезмәт актардым. Бер вариантны язам да Нил абый янына кереп укып күрсәтәм, икенче вариантны язам да аңа укып күрсәтәм. Менә шул чакта Нил абый миңа фәнни хезмәтләргә бәяләмә язуның бөтен серләрен өйрәтте, галим кешенең үз язу стилен камилләштерү өстендә ничек эшләргә тиешлеген аңлатты. Шушы вакыйгадан соң мин кемнең генә фәнни хезмәтләренә (хәтта үземнең укытучыларымның хезмәтләренә дә), нинди генә авторефератларга бәяләмә язмадым (ә андый бәяләмәләр миндә хәзер җитмештән артык), әмма минем шушы З. Ш. Хәсәнова хезмәтенә Нил абый белән киңәшә-киңәшә бәяләмә язуым гомерем буена онытылмаслык хатирә булып калды.

Нил абый һәрвакыт мөлаем, ягымлы, кешелекле, үз хезмәткәрләренә гаҗәеп игътибарлы, ярдәмчел һәм бик

сабыр җитәкче иде. Шунысы хәтеремдә уелып калган: ул, интеллигентларга хас булганча, һәрвакыт чиста, пөхтә киенеп йөри, һәрвакыт галстуктан иде. Нинди генә ситуация булмасын, ул бервакытта да тавышын да күтәрми, кызып та китми, һәрвакыт сабыр, тотанаклы булып кала белә иде. Тормыш булгач, төрле хәлләр була – безнең әдәбият секторында да ул елларда сирәк кенә булса да эреле-ваклы конфликтлы ситуацияләр дә чыккалый иде. Мәсәлән, һәр ай саен безнең даими бүлек утырышлары була, һәм аларда без үзебезнең хезмәттәшләребезнең төрле фәнни җыентыклар өчен, яки план буенча язылган (аеруча күптомлы «Татар әдәбияты тарихы» дигән күмәк хезмәткә адресланган) хезмәтләр тикшерелә иде. Шул фикер алышулар вакытында кайчакта хезмәткәрләр арасында фәнни фактларга, аларны аңлату һәм бәяләүгә үзе кебек карамаган, үзе кебек фикер йөртмәгән кешеләргә ачуы килеп чыгыш ясаучылар да табыла иде. Андый чыгышлар, гадәттә, тыныч кына һәм җитди генә бара торган фикер алышуга ниндидер киеренкелек, нервозлык төсмере бирә башлый иде. Андый вакытларда Нил абый аеруча сабыр була; ачулы кешегә ул һәр галимнең үз фикере булырга һәм ул фикер әлеге фәнни проблеманы төрле яктан, күпкырлы итеп өйрәнүгә нигезләнгән булырга тиешлеген искәртә һәм фән өлкәсендә шәхси мәнфәгатьләрне куздә тоту булырга тиеш түгеллеге, башкаларны нәкъ менә синеңчә уйламаган, синеңчә фикер йөртмәгән өчен битәрләргә, ачуланырга ярамавы турында тыныч кына аңлата иде. Шул чакларда Нил абыйның сабырлыгына сокланып, аның өчен горурланып утыра идем.

Нил Юзиев гаять күп эшләде һәм татар әдәбияты, татар тәнкыйте, әдәбият теориясе, текстология, дәреслекләр язу һәм башка күп өлкәләрдә зур хезмәтләр язып калдырды. Әдәбият бүлегенә җитәкче булып нәкъ менә ул килгәч, татар әдәбиятының күп гасырлык тарихына багышланган фундаменталь хезмәт – алты томлы «Татар әдәбияты тарихы» очеркларын язу мәсьәләсе күтәрелде. Нәкъ менә Нил Юзиевның фәнни җитәкчелегендә шушы алты томлыкның план-проспекты төзелде, аның турында фикер алышу үткәрелде, материалларны томнарга бүлү, очеркларны язуга Татарстан галимнәрен генә түгел, ә бөтен СССР күләмендәге галимнәрне тарту мәсьәләләре каралды һәм уңай хәл ителде. Ул елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты гигант бер төзелеш мәйданын хәтерләтә иде. Барлык галимнәрнең эшчәнлеге шушы алты томлыкны барлыкка китерүгә юнәлтелде. Шундый уртак тырышлык белән татар тарихында беренче тапкыр күп томлы «Татар әдәбияты тарихы» дигән монументаль хезмәт барлыкка килде. Бу хезмәт үз халкыбызга да, башка халыкларга да күп гасырлык татар әдәбиятының гаять киң планлы, киң масштаблы зур панорамасын ачып күрсәтте. Һәм бу хезмәтнең барлыкка килүендә шушы алты томлык редколлегиясенең баш редакторы Нил Юзиевның роле гаять зур һәм әһәмиятле булды.

Нил абый һәрвакытта да галимнәр яза торган фәнни хезмәтләрнең халыкка хезмәт итәргә, аның белемен арттыруга, дөньяга карашын киңәйтүгә, аңа белем бирүгә юнәлтелгән булырга тиешлегенә аеруча басым ясап әйтә иде, фәнни хезмәтләрнең

нәтиҗәлелегенә, халык арасында танылу алуына ирешергә омтыла иде. Галим фәнгә генә түгел, ә халыкка хезмәт итәргә тиеш, халыкка белем таратырга тиеш. Шушы күзлектән карап, Нил Юзиев татар язучыларының мирасын күп томлы әсәрләр итеп бастырып чыгару эшен оештыруга гаять зур тырышлык куйды. Нәкъ менә аның җитәкчелегендә әдәбият галимнәре татар классик язучыларының иҗади мирасларын барладылар, тарихта беренче тапкыр ул әсәрләрнең дөрес, фәнни-ышанычлы текстларын барлыкка китерделәр, аларга аңлатмалар яздылар һәм күп томлы әсәрләр җыелмаларын хәзерләп бастырып чыгардылар. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның сигез томлыгы, Г. Тукай һәм Ә. Фәйзинең биш томлыклары, Ф. Әмирхан, М. Гафури, М. Җәлилләрнең дүрт томлыклары, Г.Камал, Ш. Камал, Һ. Такташларның өч томлыклары, әдәбият тарихы, текстология һәм башка мәсьәләләргә багышланган мәкаләләр җыентыклары, һ. б. Аларның барысын бергә җыйсаң, тулы бер зур китапханә барлыкка килә. Минемчә, Нил абый Юзиевның бу өлкәдәге фәнни җитәкчелек эшенә бүгенгә кадәр тиешле бәя бирелгәне юк әле. Киләчәктә моңа һичшиксез тиешле бәя бирелер дип ышанам.

1978 елда мин Казаннан Алабугага күчеп киттем һәм Алабуга педагогия институтында укыта башладым. Ләкин аннан соң да минем Нил абый Юзиев белән элемтәм һәм аралашып, фикерләшеп яшәвем туктамады. Мин еш кына Нил абыйга шалтыратып, яңалыклар белән уртаклашып яшәдем. Казанга барган чакта исә мин бервакытта да үземә канат куйган фәнни җитәкчем белән очрашмыйча, үзем эшләп алган институтка кермичә китми идем. Ә безнең аның белән сөйләшердәй сүзләребез, яңалыкларыбыз һәрвакыт күп булып җыелып тора иде. Нәкъ менә Казаннан киткәч, Нил абый белән киңәшә-киңәшә мин үземнең элек эшләгән фәнни тема – Габдерәхим Утыз Имәни шигъри әсәрләренең текстологиясе өстендә эшләвемне дәвам иттем: ул әсәрләрнең бик җентекләп фәнни-чагыштырма текстларын төзедем һәм аларны 1986 елда Татарстан китап нәшриятында «Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари. Шигырьләр, поэмалар» исеме белән бастырып чыгардым.

Нил абый үзе дә ул елларда, сирәк булса да, Алабуга институтына килеп, лекцияләр укып, укытучылар һәм студентлар алдында чыгышлар ясап киткәли иде. Үземнең көндәлеккә мин аларны да теркәп барганмын. Мәсәлән, минем көндәлектән берничә өзек:

«1979 ел, 26 июль. Алабугага Нил абый килеп чыкты. Аңа Алабуганы күрсәтеп йөрдем.»

«1982 ел, 11 июнь. Чаллыда татар телен һәм әдәбиятын вузларда укыту мәсьәләләре буенча фәнни-гамәли конференция булды. «Энергетик» мәдәният сараенда әдәбият буенча программалар тикшердек. Аннан соң мин Нил абый Юзиевны һәм Үзбәк абый Гыймадиевны үземә чакырдым. Сөйләшеп утырдык. Соңыннан аларны «Татарстан» кунакханәсенә озатып куйдым.»

«1983 ел, 17 март. Казанга бардым. Нил абый Юзиевны, Рәис Даутовны күреп сөйләштем.»

«1985 ел, 10 апрель. Алабуга пединститутына Нил абый Юзиев килде. Аның белән кунакханә бүлмәсендә бер сәгатькә якын сөйләшеп утырдык.»

«1985 ел, 11 апрель. Нил абыйны үземә алып килермен дип әзерләнеп йөргән идем дә, булмады. Чаллыга килергә вакыты юк, вакыты бик тыгыз.»

«1986 ел, 25 сентябрь. Нил абыйны «Почет билгесе» ордены белән бүләкләгәннәр. Аңа котлау телеграммасы җибәрдем.»

«1987 ел, 14 май. Нил абый Алабуга techинституты студентлары белән очрашу үткәрде. Мин дә катнаштым. Очрашудан соң Нил абый белән кунакханәдәге аның бүлмәсендә сөйләшеп утырдык.»

Шундый очрашуларның тагын берсен әйтеп үтәсем килә. 1994 елның җәендә Нил абый тагын Алабуга пединститутына лекция укырга килгән иде. Ул һәрвакыттагыча шат күңелле, вакыт-вакыт ютәлләп алуына да карамастан, шаян сүзле дә иде. Шул чакта мин аның чәчләренә игътибар иттем. Аның як-яктан салынып төшкән чәчләре миңа һәрвакыт ни өчендер Такташ чәчләрен хәтерләтә иде. Шунда мин үземнең – аның укучысының – чәчемнең инде агара баруына, ә аның чәченең әле һаман шул көе – чем-кара булып калуына игътибар иттем. Нил абыйның чәче аның соңгы көннәренә кадәр шулай чем-кара булып калды.

Бу килүендә мин аны, җай табып, Чаллыга, үземә кунакка чакырдым. Ул килде. Ул чакта минем Таңчулпан исемле кызыма дүрт яшь тә тулмаган иде әле. Безнең өйгә килеп кергән һәр кешедән кызым әле ятсына. «Кил әле, кил әле!» – дип чакырсаң да, кача, әнисе Фәйрүзәнең итәге артына яшеренә иде. Ә бу юлы алай булмады. Нил абый кереп диванга утырырга да өлгермәде, Таңчулпан, әле чакыруны да көтеп тормыйча, Нил абыйның алдына килеп тә утырды. Бу хәлгә без барыбыз да бик гаҗәпләндек. «Ничек алай тиз үзләште әле безнең кызыбыз», – дип көлештек. Бу вакыйга безгә Нил абыйның эчкерсез, саф күңелле, йомшак табигатьле, бала җанлы булуын бик ачык гәүдәләндерде. Әйе, сабый бала яхшы күңелле, эчкерсез кешене тиз таный, бик тиз үзләшә шул.

Шушы очрашуда Нил абый Таңчулпанга күзе ачыла да, йомыла да торган, мәктәп укучысы формасы кигән бик матур бер зур курчак бүләк итте. Таңчулпан ул курчакны бер дә ватмыйча уйнады, ул бездә әле дә саклана. Шушы бер очрашу дүрт яшьлек бала күңеленә дә кереп, сеңеп калган. Нил абыйсының алдында утыруын Таңчулпан әле дә хәтерли.

1994 елны Нил абый миңа үзенең «Татар шигыре» дигән китабын бүләк итте. Китапка: «Әнвәр дуска – иҗаттагы һәм фәндәге уңышлары өчен шатланып, Казанда һәм Чаллыда очрашулар истәлеге итеп, уңышлар теләп, автордан. Юзиев. 18. III. 94.» – дип язып бирде.

Менә шундый гаҗәеп якын күреп, һәрвакыт аралашып-киңәшләшеп яшәгән, үземә авыр чакта аңа барып егыла, шатлыгым булганда эчкерсез уртаклаша торган бертуган абыем кебек иде Нил Юзиев минем өчен! Мин аны еш кына безнең өйдә диванда, Таңчулпан кызымны алдына алып, аның башыннан сөеп, аның белән сабыйларча ихлас күңелдән сөйләшеп утырган кыяфәттә күз алдына китерәм. Әйе, ул чыннан да безнең гаилә кешесе кебек иде шул. Урыны җәннәттә булсын.